**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мэлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мэлбагыш авылы № 125 3 март 2015 ел.

Мэлбагыш авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Мэлбагыш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Мэлбагыш авылы башкарма комитетының 25 февраль 2015 елда чыккан 36 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Мэлбагыш авыл җирлеге Советының 28 февраль 2015 елда чыккан 124 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Мэлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте :

1. Мэлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 апрель 2015 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Мэлбагыш авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2015 елда 200 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - авыл эчендәге юлларны, күперләрне ремонтлау, игътибар үзәгендә тоту.;
   - авыл жирлеге билэмэлэрендэ беренче янгын куркынычсызлыгын тэймин иту;
   - авыл жирлеге билэмэсен тозеклэндеру очен ( урамнарны яктырту, кышын юлларны кардан арындыру, зиаратларнын ихатасын ныгыту, территорияне яшеллэндеру, урамнарга һэм йортларга урам исемнэре, йорт номерлары урнаштыру, кечкенэ архитектура формалары кую һэм тозеклэндеру)
   - халыкнын ялын оештыру һэм мэдэни оешмалар хезмэтлэрен курсэтуне тэймин иту очен шартлар тудыру.

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: И.А.Ахтямова